РЕСПУБЛИКА ТАТАРСТАН
НИЖНЕКАМСКИЙ
ГОРОДСКОЙ СОВЕТ
пр. Строителей, д. 12, г. Нижнекамск, 423570

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
ТҮБӘН КАМА
ШӘҺӘР СОВЕТЫ
Төзүчеләр пр., 12 нче йорт, Түбән Кама шәһәре, 423570

Тел./факс: (8555) 42-42-66. E-mail: Gorsovet.Nk@tatar.ru

**РЕШЕНИЕ** **КАРАР**

2022 елның 14 феврале № 11

Түбән Кама шәһәр Советының 2009 елның 28 гыйнварындагы 5 номерлы карары белән расланган Түбән Кама шәһәре муниципаль берәмлегендә бюджет процессы турындагы нигезләмәгә үзгәрешләр кертү хакында

«Россия Федерациясе Бюджет кодексына үзгәрешләр кертү турында» 2021 елның 1 июлендәге 251-ФЗ номерлы һәм «Россия Федерациясе Бюджет кодексына һәм Россия Федерациясенең аерым закон актларына үзгәрешләр кертү һәм 2022 елда Россия Федерациясе бюджет системасы бюджетлары үтәлеше үзенчәлекләрен билгеләү турында» 2021 елның 29 ноябрендәге 384-ФЗ номерлы Федераль законнар нигезендә, Түбән Кама шәһәр Советы

КАРАР БИРӘ:

1. Түбән Кама шәһәр Советының 2009 елның 28 гыйнварындагы 5 номерлы карары белән расланган Түбән Кама шәһәре муниципаль берәмлегендә бюджет процессы турындагы нигезләмәгә түбәндәге үзгәрешләр кертергә:

1.1. 5 статьяга түбәндәге эчтәлекле абзац өстәргә:

«- гражданнарның бюджет процессында катнашуы.»;

1.2. 13 статьяның 1 пунктындагы 11 абзацында, 28 статьяның 2 пунктындагы 4 абзацында «әлеге Кодекс белән» сүзләрен «Россия Федерациясе Бюджет кодексы белән» сүзләренә алмаштырырга;

1.3. 22 статьяның бишенче абзацын түбәндәге редакциядә бәян итәргә: «Бурыч алуларның иң чик күләме Россия Федерациясе Бюджет кодексының 106 статьясы таләпләре нигезендә билгеләнә»;

1.4. 23 статьяның 2 пунктын түбәндәге редакциядә бәян итәргә: «2. Бюджет проекты Россия Федерациясе Бюджет кодексының 172 статьясында һәм Татарстан Республикасы Бюджет кодексының 53 статьясында билгеләнгән нигезләмәләр, белешмәләр һәм документлар нигезендә төзелә.»;

1.5. 28 статьяның 2 пунктындагы 2 абзацына «Россия Федерациясе Бюджет кодексының 160.1 статьясында каралган очракларда» сүзләрен өстәргә;

1.6. 28 статьяның 2 пунктындагы 3 абзацында «Россия Федерациясе Бюджет кодексының 160.2 статьясында каралган очракларда» сүзләрен өстәргә;

1.7. 34 статьяның 4 пунктына түбәндәге эчтәлекле абзац өстәргә:

«-электрон сертификаттан файдаланып сатып алына торган товарларның, эшләрнең, хезмәт күрсәтүләрнең аерым төрләренә түләүгә агымдагы финанс елының бюджет ассигнованиеләре арткан очракта, федераль законда билгеләнгән очракларда, агымдагы финанс елы башына Россия Федерациясе Бюджет кодексында билгеләнгән таләпләр нигезендә әлеге максатларга файдаланылмаган бюджет ассигнованиеләренең калдыгыннан артмаган күләмдә.»;

1.8. 43 статьяның 4 пунктына «, әгәр Россия Федерациясе Бюджет Кодексында башкача каралмаган булса» сүзләрен өстәргә;

1.9. 19 статьяның 15 абзацы, 22 статьяның 1 пунктындагы икенче абзац үз көчен югалткан дип таныrга.

2. Түбән Кама шәһәр Советының 2009 елның 28 гыйнварындагы 5 номерлы карары (әлеге карар редакциясендә) белән расланган Түбән Кама шәһәре муниципаль берәмлегендә бюджет процессы турындагы Нигезләмәнең 28 статьясындагы 2 пунктының 2 һәм 3 абзацларының нигезләмәләре 2022 елга һәм 2023 һәм 2024 еллар план чорына (2022 елга) бюджетлардан башлап, җирле бюджетны төзегәндә һәм үтәгәндә барлыкка килгән хокук мөнәсәбәтләренә карата кулланыла.

3. Әлеге карар рәсми басылып чыккан көненнән үз көченә керә.

4. Әлеге карарны массакүләм мәгълүмат чараларында бастырып чыгарырга һәм Түбән Кама муниципаль районының рәсми сайтында урнаштырырга.

5. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны Түбән Кама шәһәр Советының бюджет сәясәте һәм икътисадый үсеш буенча даими комиссиясенә йөкләргә.

Түбән Кама шәһәре Мэры
вазыйфаларын башкаручы,
Мэр урынбасары М.В. Камелина